ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

11 07 2022 г. № 426

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә расланган стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына кертелгән стационар булмаган сәүдә объектларын торглар үткәрмичә урнаштыру өчен шартнамәләр төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 9 апрелендәге 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон (2022 елның 8 мартындагы редакциядә) нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә расланган стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына кертелгән стационар булмаган сәүдә объектларын торглар үткәрмичә урнаштыру өчен шартнамәләр төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 9 апрелендәге 393 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункт өстәргә:

«1.5. Алдан күрү (проактив) режимында муниципаль хезмәт күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Алдан күрү (проактив) режимында муниципаль хезмәтләр, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аңа әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан күрү (проактив) режимында бирү турында алдан сорату бирү шартында һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган

тарафыннан 210-ФЗ номерлы Федераль законның $7^3$ статьясындагы 1 өлеше нигезендә чаралар гамәлгә ашырылганнан соң, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтү бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/) техник мөмкинлекне гамәлгә ашыру юлы белән күрсәтелә.

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Алдан күрү (проактив) режимында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтү бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша муниципаль хезмәтләр күрсәткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынган белешмәләр һәм әлеге пунктта каралган документлар файдаланыла.»;

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре» бүлегендә:

«3.8.2, 3.8.3» пунктчаларын номерлауны «3.7.2, 3.7.3» кә алмаштырырга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

Җитәкче Р.Х. Муллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МКУ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ *
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874